**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 28 маендагы 1820 номерлы карары**

**Казан шәһәрендә «Ак Барс Арена» стадионында концерт үткәрү чорында транспорт чаралары хәрәкәтен һәм туктап торуын чикләү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 18 апрелендәге 353 номерлы «Рәсми спорт ярышлары уздырганда куркынычсызлыкны тәэмин итү кагыйдәләрен раслау турында»гы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы «Төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә туктатуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә, «ШоуМейкерс групп» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры Т.Р.Нуруллинның 2025 елның 22 апрелендәге хатын исәпкә алып:

1. **Карар бирәм**:

1.1. ихтыяҗ булганда, 2026 елның 6 июнендә 06:00 сәгатьтән 23:59 сәгатькә кадәр «Ак Барс Арена» стадионы тирәсендәге әйләнеч юлда, «ШоуМейкерс групп» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – Оештыручы) тарафыннан билгеләнгән форма буенча тутырылган махсус рөхсәт кәгазьләре белән җиһазландырылган транспорт чараларыннан тыш, транспорт чаралары хәрәкәтен һәм туктап торуын чикләргә;

1.2. юл хәрәкәтен оештыруда техник чараларны һәм таранга каршы техниканы урнаштыру өчен Оештыручы җаваплы дип билгеләргә;

1.3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитетына (А.М.Шәйнуров) Казан шәһәре Башкарма комитетының Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары администрациясе белән берлектә (Р.Х.Шәмсетдинов) Оештыручыга йөк техникасы һәм (яисә) таранга каршы блоклар бирүдә ярдәм күрсәтергә;

1.4. Казан шәһәре Башкарма комитетының Транспорт комитетына (А.В.Сидоров):

1.4.1. вакытлыча юл билгеләрен урнаштыруда һәм гамәлдәге юл билгеләрен каплауда Оештыручыга ярдәм күрсәтергә;

1.4.2. транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны вакытлыча чикләү турындагы мәгълүматны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы рәсми порталы» дәүләт мәгълүмат системасы составына керә торган рәсми сайтында урнаштырырга;

1.4.3. кыска вакытлы аренда хезмәте күрсәтә торган электр самокатлары (WHOOSH һәм MTC.URENT) һәм велосипед («Яшел шәһәр») операторлары белән берлектә әлеге карарның кушымтасында күрсәтелгән участокта шәхси мобильлек чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны тыю эшен оештырырга;

1.5. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

2. **Тәкъдим итәм**:

2.1. Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә (Р.Д.Габитов) әлеге карар нигезендә Казан шәһәре урам-юл челтәренең югарыда күрсәтелгән участогында юл хәрәкәте иминлеген саклауны һәм оештыру-көйләү гамәлләрен башкаруны контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

2.2. Казан шәһәре Думасы аппаратының Мәгълүмат-аналитика идарәсенә (В.А.Казанцев) Казан шәһәре урам-юл челтәренең күрсәтелгән участогында транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны вакытлыча чикләүне кертү турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка **йөклим**.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 28 маендагы
1820 номерлы карарына
кушымта

